**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты
карары**

**№3087
26.06.2020**

Башкарма комитетның 2011 елның 12 апрелендәге 1816 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәтен арендага бирү процедурасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Конкурентлыкны яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясы, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2011 елның 12 апрелендәге 1816 номерлы карары (Башкарма комитетның 2011 елның 23 августындагы 4493 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәтен арендага бирү процедурасы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 18 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «18. Арендага алучы муниципаль мөлкәткә карата әлеге нигезләмәнең 12 пункты нигезендә бирелгән хуҗа булу һәм (яки) файдалану хокукларын милек хуҗасының ризалыгы буенча сатулар үткәрми генә субарендага бирергә хокуклы»;

2) 19 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «19. Муниципаль мөлкәт буенча субаренда шартнамәсе муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәсенең гамәлдә булу вакытыннан артмаган срокка төзелә. Арендага алучы субарендага бирелүче муниципаль мөлкәтнең сакланышы һәм аннан субаренда шартларында файдаланган өчен түләүләрнең вакытында кертелүе өчен җавап бирә. Субарендага алучы түләүне Арендага алучының исәп-хисап счетына күчерә».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый

мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), шәһәрнең рәсми сайтында (www.nabchelny.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов